Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл Советы

КАРАРЫ

2019 ел 14 май

№ 114

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл җирлеге
Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставының XIV бүлеге, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2019 елның 14 мартындагы күрсәтмәләре һәм 2019 елның 19 апрелендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләрен исәпкә алып

Яңа Никольский авылы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләрне теркәгәннән соң Новоникольск авылы, Үзәк урам, 100 нче йорт; Салкын Алан авылы, Луговая урамы, 60 нчы йорт; Иштирәк авылы, Чишмә урамы, 3 нче йорт; Хазовка, Болтаево, Завод, Кәминкә, Кече Шуган, Поташная Поляна, Сосновка, территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка хәбәр итәргә, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ Федераль законның 44 статьясы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Никольский авыл җирлеге
башлыгы

Х.Х. Дәүләтгәрәев

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы
Яңа Никольский авыл Советының
2019 елның 14 маендагы № 114
карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл җирлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында

1) 5 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«4. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары җирлек өчен социаль әһәмияткә ия булган эшләрне (шул исәптән дежур торуны) ирекле нигездә башкаруга җәлеп итү максатларында әлеге статьяның 1 өлешендәге 4, 8, 9 пунктлары нигезендә карарлар кабул итәргә хокуклы.»

2) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 15 пунктта «күзәтүчесез хайваннарны аулау һәм тоту буенча чаралар» сүзләрен «хуҗасыз хайваннар белән мөгамәлә итү буенча эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга»;

б) 18 пунктка түбәндәге эчтәлекне өстәргә:

«18) 1992 елның 7 февралендәге «кулланучылар хокукларын яклау турында» №2300-1 Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.»;

3) 13.1. статьяны түбәндәге эчтәлектәге 7.1. өлеше белән тулыландырырга:

«7.1. Әлеге статьяда каралган җыен торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда үткәрелергә хокуклы. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артык өлеше белән бер ук вакытта халык җыены үткәрү мөмкин булмаса, Устав нигезендә ул этаплап, җыен үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан артмаган вакытта үткәрелә. Үткән гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Халык җыены карары, җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.

4) 15 статьяның 4 өлешендә «әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 34 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләренә алмаштырырга;

6) 40 статьяның 4 өлешендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләренә алмаштырырга;

7) 43 статьяда:

а) 11пунктның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

1992 елның 7 февралендәге «Кулланучылар хокукларын яклау турында» №2300-1 Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.»;

б) 4 пунктның 1 өлеше өченче абзацында «торак биналарны яңадан планлаштыру» сүзләрен «күпфатирлы йортта биналарны яңадан планлаштыру" сүзләренә алмаштырырга»;

в) 2 өлешнең унөченче абзацында «хуҗасыз хайваннарны аулау һәм тоту буенча чаралар» сүзләрен «хуҗаларсыз хайваннар белән мөгамәлә итү буенча эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга»;

8) 56 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

в) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

г) 5 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

д) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

е) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

ж) 11 өлешнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) сүзләрен өстәргә)»;

з) 14 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Премьер-министры) " сүзләрен өстәргә.

9) 82 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Җирлек халкы саны артуга яки кимүгә бәйле рәвештә, җирлек Советы депутатлары санын арттыручы яки киметүче үзгәрешләр әлеге үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт кабул иткән җирлек Советы вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.»

Яңа Никольский авыл җирлеге
башлыгы Х.Х. Дәүләтгәрәев